ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 115-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
2. «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 116-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
3. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 119-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 117-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 118-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. Профессиональ даими нигездә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын сайлау турында.
7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым комитетлары составларындагы үзгәрешләр турында.
8. Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Идел-Кама регионара идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат.
9. Махсус хәрби операциядә катнашучы абонентка бирелгән абонент номеры (номерлары) буенча элемтә хезмәтләреннән файдаланмаган очракта,

кәрәзле элемтә хезмәтләрен күрсәтү турындагы шартнамәне элемтә операторы тарафыннан берьяклы тәртиптә өзүгә тыю билгеләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Брянск өлкә Думасы мөрәҗәгате хакында.

10. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү өлкәсендәге программаларны гамәлгә ашыру турында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмммәтшин

Түбән Кама шәһәре
2025 елның 23 октябре
№ 122-VII ДСП